ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Тел./факс: (85556) 2-57-52, e-mail: landysh.sayfullina@tatar.ru, http://muslumovo.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.01.2021 г. Мөслим №12

**«Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 574 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2020 елның 18 декабрендәге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе коллегиясенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча беркетмә йөкләмәсен үтәү максатларында, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 574 номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибендәге 2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «12» абзацын өстәргә:

«12) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында салым органы белешмәсе (белешмәләре).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресындагы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында районның рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы